ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.12.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4099**

«Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары мөлкәтен тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар исәпләү тәртибен раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 июлендәге 1653 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 07 сентябрендәге 1092 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары мөлкәтен тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 13 июлендәге 1653 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары мөлкәтен тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибенә (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 мартындагы 568 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. - 2.9 пунктның өченче абзацында :
«планнан алда килә торган» сүзләрен «планлаштырыла торган чорга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;
«һәм план чоры» сүзләрен өстәргә;
1.2. - 2.11 пунктының унбишенче абзацында:
«планнан алда килә торган» сүзләрен «планлаштырыла торган чорга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;
«һәм план чоры» сүзләрен өстәргә.
2. Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

4. Әлеге карар, 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына норматив чыгымнардан башлап, тиешле норматив чыгымнар билгеләгәндә барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә карата кулланыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин